ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01 август, 2019 ел № 32/13

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 маддәләре нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 08 декабрендәге 6/5 санлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 04 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 09 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 05 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/10, 2017 елның 22 февралендәге 15/10, 2017 елның 10 августындагы 18/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/16, 2018 елның 27 апрелендәге № 24/8, 2018 елның 11 декабрендәге №28/9 санлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) **9 маддәнең 1 өлешендә:**

– **7.2 пунктында** «милли азчылыкларның» сүзләреннән соң «аз санлы җирле халыкларның һәм башкаларның» сүзләрен өстәргә;

– **33 пунктта** «киңәйтү өчен» сүзләреннән соң «,авыл хуҗалыгы производствосын үстерү өчен» сүзләрен өстәргә;

- **43 пунктта** «дәүләтнең күчемсез милек кадастры» сүзләрен «кадастр эшчәнлеге» дип үзгәртергә;

2) **9.1 маддәнең 1 өлеше 15 пунктында** «караучысыз хайваннарны тотып алу һәм карап тоту буенча чараларны гамәлгә ашыру» сүзләрен «хуҗасыз хайваннар белән эш итү» сүзләренә алыштырырга;

3) **10 маддәнең 1 өлеше 5 пунктын** көчен югалткан дип танырга;

4) **17 маддәнең 3 өлешен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория чикләре әлеге территориядә яшәүче халык тәкъдиме буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә.»;

5) **27 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 1.1** өлеше белән тулыландырырга:

«1.1 Шәһәр халкы саны арту яки кимүгә бәйле рәвештә, Шәһәр Советы депутатлары санын арттыручы яисә киметүче үзгәрешләр, күрсәтелгән үзгәрешләр кертү турында муниципаль норматив хокукый актны кабул иткән Шәһәр Советының вәкаләтләре вакыты тәмамланганнан соң үз көченә керә.»;

6) **28 маддәнең 2 өлешендәге 53, 70** пунктларны көчен югалткан дип танырга;

7) **31 маддәнең 7 өлешен** түбәндәге эчтәлектәге өченче абзац белән тулыландырырга:

«Вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә эш урынында булмаган вакытта, аларның төп эш урынындагы хезмәт хакы саклана.»;

8) **34 маддәнең 7.1 өлешен** көчен югалткан дип танырга;

9) **35 маддәдә:**

**– 1 өлешне түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пункты белән тулыландырырга**:

«2.1) җирле үзидарә органнары эшчәнлеген оештыру буенча муниципаль хокукый актлар чыгара;»;

**– 2 өлешнең 21 пунктындагы «г» пунктчасын** түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«г) җирле салымнарны билгеләүне, үзгәртүне һәм бетерүне, шәһәр бюджетыннан чыгымнарны гамәлгә ашыруны күздә тоткан Шәһәр Советы карарлары проектларын»;

10) **37 маддәнең 3.2 өлешен** көчен югалткан дип танырга;

11) **41 маддәдә:**

**– 4 өлешнең 28 пунктында** «дәүләтнең күчемсез милек кадастры»сүзләрен «кадастр эшчәнлеге» дип үзгәртергә;

**– 7 өлешнең 1 пунктын** түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«1) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өчен кирәкле көчләрне һәм чараларны әзерләү һәм карап тоту, шулай ук халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклануга әзерләү;»;

**– 7 өлешнең 7.2 пунктында** «3 пункттагы» сүзен «8 пункттагы» дип үзгәртергә;

– **9 өлешне** түбәндәге эчтәлектәге **9.22 һәм 9.23** пунктлары белән

тулыландырырга:

«9.22) торак-коммуналь хуҗалыкны, сәнәгать һәм башка оешмаларны газлаштыруның төбәкара һәм региональ программалары нигезендә халыкны газ куллануга әзерләү;

9.23) халыкны газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган газ белән тәэмин итү объектларын урнаштыру схемаларын килештерү;»;

– **9 өлешнең 14.6 пунктында** «караучысыз хайваннарны тотып алу һәм карап тоту буенча чараларны гамәлгә ашыру» сүзләрен «хуҗасыз хайваннар белән эш итү» сүзләренә алыштырырга;

– **9 өлешне** түбәндәге эчтәлектәге **19.1 пункты** белән тулыландырырга:

«19.1) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;»;

**– 9 өлешнең 24.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге дүртенче абзац белән тулыландырырга :**

«ел саен (хисап елыннан соң килүче елның 1 июленә кадәр) юлларның һәләкәтле участокларының исемлеген раслау һәм юл-транспорт һәлакәтләренең сәбәпләрен һәм шартларын бетерүгә юнәлдерелгән беренчел чаралар эшләү;»;

– **10 өлешнең 7 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) күп фатирлы йортта торак планын үзгәртүне һәм торакны үзгәртеп коруны килештерү;»;

– **10 өлешне** түбәндәге эчтәлектәге **10 пункт** белән тулыландырырга:

«10) күп фатирлы йорттагы торакларны үзгәртеп кору һәм яңача планлаштыру шартлары һәм тәртибе нигезендә, күп фатирлы йорттагы торакларны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп кору планын килештерү турында карар кабул итүне раслауны яки инкарь итүне дәлилләүче документны алу тәртибен билгеләү»;

– **11 өлешнең 13 пунктында** «шартлар тудыру» сүзләреннән алда «авыл хуҗалыгы җитештерүе үсеше өчен» сүзләрен өстәргә;

– **13 өлештә:**

**7 пунктта** «хокуклары» сүзеннән алда «җир аз санлы халыкларның һәм башкаларның» сүзләрен өстәргә;

**10 пунктны** көчен югалткан дип танырга;

12) **42 маддәнең 1 өлеше 4 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) җирле салымнарны билгеләүне, үзгәртүне һәм гамәлдән чыгаруны, шәһәр бюджетыннан чыгымнарны гамәлгә ашыруны күздә тоткан Шәһәр Советы карарлары проектларын, билгеләнгән тәртиптә, Шәһәр Советына кертә;»;

13) **48 маддәдә:**

– **7 өлештә 1.1, 4-8 пунктларын** көчен югалткан дип танырга;

– **8** өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Әлеге маддә нигезендә муниципаль хезмәткәрләргә бирелүче

гарантияләрне бирү тәртибе һәм шартлары шәһәр Хакиме тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге Карар матбугатта рәсми басылган көннән үз көченә керә, нигезләмәләр өчен үз көченә керү гамәлдәге законнар белән башка вакытта каралган.

3. Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевкә әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә тапшырырга.

4. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме — Н.Г. Мәһдиев

ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2019 елның 22 августында теркәлде. Дәүләт теркәве номеры RU 163020002019001.